| ГЛАВА<br>Бимского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Бима авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.10.2024 Бима авылы № 16

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бима авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Бима авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Бима торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын 2024 елның 30 октябрь көнне 14 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Бима авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Бима торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар (80 яшькә җиткән), студентлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле рәвештә киткәннәрдән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (аларның ата-аналарын, хатыннары, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итеп һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне үтәү буенча алынган мәсьәләләрне хәл итүгә юллап, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдереп, гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: 2025 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертү һәм куллану белән килешәсезме?”: